


26-27 мартта Казаннын Вахитов районындагы К.Насый-ри исемендәге 80 номерлы татар-рус урта мәктәбе базасында Ботенроссия белем бирv оешмалары һәм якшәмбе мәктәпләренен туган тел укытучылары конкурсы vткән. Бәйге 2007 елдан бирле уздырыла.

Конкурснын максаты – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы халыкларынын телләре һәм мәдәниятләре кvпторлелеген саклап калуга һәм vстерvгә ярдәм итv, туган тел укытучыларынын абруен арттыру, педагогик тәжрибә һәм һонәри осталыкны тарату.      Конкурснын читтән катнашу этабында Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан 69 туган тел укытучысы һәм Россия Федерациясе субъектларыннан 12 туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы катнашкан. Йомгаклау этабына 50 туган тел һәм әдәбият укытучысы, шул исәптән 16 туган татар теле укытучысы, 8 туган рус теле укытучысы, 7 туган чуваш теле укытучысы, 3 туган мари теле укытучысы, 3 туган удмурт теле укытучысы, 1 туган мордва теле укытучысы һәм Россия Федерациясенен башка субъектларыннан 12 туган татар теле һәм әдәбияты укытучысы узган.

Бу ярышта катнашкан Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбенен татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы Альфия Фатих кызы Муртазина, башка регионнардан килгән коллегалары белән бергә “Масстер-класс” (конкурсантнын гамәли эшендә vзенен нәтижәлелеген исбатлаган һонәри эшчәнлек ысулларын кvрсәтvче чыгыш) кvрсәтә, класстан тыш эшенен проектын яклый, тvгәрәк остәлдә катнаша һәм нәтижәдә икенче призлы урынны яулый.

Алда тагы зур унышлар сезгә, Альфия Фатиховна!

**Наилә НАСЫРОВА**